**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Әлки**
**муниципаль районы**
**Югары Колчура авыл җирлеге**
**Башкарма комитеты**

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**Исполнительный комитет**
**Верхнеколчуринского сельского**
**поселения Алькеевского**
**муниципального района**

Адресы: 422873, ТР, Әлки
районы, Югары Колчура авылы,
Март 8 урамы, 21 йорт
Тел/Факс 8 (84346) 78014

422873, РТ, Алькеевский район,
с. Верхнее Колчурино, ул. 8 Марта,
д.21
Тел/Факс 8 (84346) 78014

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** Югары Колчура ав. **КАРАР**

09.06.2025 ел № 12

**Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Югары Колчура авыл җирлеге территориясендә йорт хайваннарын йөртү урыннарын билгеләү турында**

06.10.2003 елның 131-нче Федераль Законы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында», 27.12.2018 елның 489-нче Федераль Законы «Хайваннар белән җаваплы эш итү һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында», Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының «Югары Колчура авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы таянып, Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Югары Колчура авыл җирлеге Башкарма комитеты **КАРАР КАБУЛ ИТӘ:**

1. Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының «Югары Колчура авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә йорт хайваннарын йөртү өчен түбәндәге урыннарны билгеләргә:

1.1. Файдаланудагы яисә хуҗа милкендәге җир кишәрлекләре;

1.2. Халык күплән җыелмый торган авыл җирлеге территориясендә торак сектор һәм җәмәгать урыннары артындагы урыннарда, борындыкларда һәм тезгендә аларның хуҗалары күзәтүе астында:

- Югары Колчура авылының көньяк-көнчыгыш өлешендә, 1 Май урамы буйлап 100 метр ераклыкта;
- Югары Колчура авылының көньяк-көнбатыш өлешендә, 8 Март урамыннан 200 метр ераклыкта;
- Түбән Колчура авылының төньяк-көнчыгыш өлешендә Полевая урамы буйлап 200 метр ераклыкта;
- Түбән Колчура авылының төньяк-көнбатыш өлешендә, пролетариат урамы буйлап 200 метр ераклыкта.

Бу территорияләрдә «йорт хайваннарын йөртү»дигән язулы табличкалар урнаштырырга.

2. Әлеге карарны "Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында" түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru хәм Әлки муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Әлки муниципаль районының
Югары Колчура авыл җирлеге
Башкарма комитет җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы Калмыкова Н. В.